**ГЛАВА НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

422630,РТ, Лаишевский район, село Нармонка, ул.Молодежная , д.12
8-(84378) -4-62-24
факс: 8-(84378) -4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**НАРМОНКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**

422630, РТ, Лаеш районы, Нармонкаавылы, Яшьләрурамы, 12 Анчейорт
тел: 8-(84378) -4-62-24
факс: 8-(84378) -4-62-24

---

**2022елның 03 ноябре** **5 номер**

# КАРАР

**Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Карадули торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, «Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Карадули торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышын 2022 елның 26 ноябренә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә**.**

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

2023 елда яшәү урыны буенча муниципаль район авыл җирлегенең Карадули торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән(көндезге формада белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга

- Карадули авылында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуга (смета буенча юл төзелеше: таш, ком сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү (зиратка юл)) юнәлтү белән килешәсезме?

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә, махсус мәгълүмат стендларында һәм Нармонка авыл җирлегенең рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

3. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Нармонка**
**авыл җирлеге Советы рәисе :** **А.О.Солягин**